OMEGA OFFICIAL TIMEKEEPER
КӨН СӘГАТЬ МИНУТ СЕКУНД
2015 ЕЛГЫ СУ СПОРТ ТӨРЛӘРЕ БУЕНЧА 16 НЧЫ ФИНА ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНАТЫНА КАДӘР
Fina FÉDÉRATION INTERNATIONALE DE NATATION

# ЭМИЛИ СИБОМ – 100 МЕТР АРАГА АРКАДА ЙӨЗҮ БУЕНЧА ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНЫ

04.08.2015, 18:12
СПОРТ

**Бу минутларда Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты кысаларында аркада йөзү финалы тәмамланды. 100 метр арага аркада йөзүдә дөньяның иң яхшы 8 спортчы кызы ярышты.**

Алтын медальне 2 тапкыр Олимпия чемпионкасы - австралияле Эмили Сибом яулады, ул бу дистанцияне иң югары нәтиҗә белән тәмамлады – 58.26. Аннан соң финишка аның ватандашы Мэдисон Уилсон килде, 2 ел элек ул Казандагы Универсиадада беренчелекне алган иде. Аның нәтиҗәсе – 58.75. Өчлекнең соңгы призеры – Даниядән Ми Нильсен – ул бу дистанцияне 58.86та тәмамлады.

ДЧ-2015. Йөзү

Хатын-кызлар. 100 м аркада.

1. Эмили Сибом (Австралия) – 58.26

2. Мэдисон Уилсон (Австралия) – 58.75

3. Ми Нильсен (Дания) – 58.86

4 август. Казан. “Казан Арена”

Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты Оештыру комитеты матбугат хезмәте

---

ЯҢАЛЫКЛАР ТАСМАСЫН АЧАРГА